
# Корчагиннар токымын  барлыйбыз.

М.Вахитов исемендәге 2 гимназиянең “ Ал җилкәннәр” тимур отрядының чираттагы тукталышы- 36 нчы бистә, күршебездә генә яшәп ятучы Вероника гаиләсе. Фатирга кергәч тә безне күптәнге таныш-ларын каршы алган кебек каршыладылар. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәт нур булып кызның йөзенә күчкән.

Тиз арада бер-беребез белән танышып та алдык. Вероникага 17 яшь. Әтиле-әниле гаиләдә өч бала.Ул гаиләдә икенче бала икән. Үзенең семьясы, апасы Наташа һәм энесе Данила турында горурланып сөйли. Тумыштан инвалид булып туган Вероникане чын мәгънәсендә бүгенге көннең Корчагины дип атарга була.Ул үзе синтезаторда уйный, көйләр яза, рәсемнәр ясый икән. Рәсемнәрендәге матурлык, ачык төсләрдә аның күңел яктылыгы чагыла. Ул ясаган картиналар төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләргә урнаш-тырыла, призлы урыннар ала икән. Стенаны тутырып торучы Грамоталар һәм Дипломнар- Верони-каның иҗат уңышлары. Вероника тырышып инглиз телен өйрәнә. Инглиз теленнән олимпиада да җиңеп чыккан. Киләчәктә тәрҗемәче булырга хыяллана. Без аның нык характерына, һәркемгә ачык күңеленә сокланып кайттык. Вероника бу дөньяга кешеләргә яхшылык эшләү өчен җибәрелгән бер фәрештә булып күңелдә калды.

Сәлмәнова Сөмбел, Илалетдинов Алмаз, Хәйруллина Зәринә, тимурчылар. М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназия









ГРАМОТА
ГРАМОТА






Letter




ДИПЛОМ
ДИПЛОМ
ДИПЛОМ
ДИПЛОМ


ДИПЛОМ
ГРАМОТА
Диплом
Диплом
ДИПЛОМ